**СОВЕТ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2019 елның «5» августыннан — № 51-309

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2014 елның 16 декабрендәге 38-228 номерлы «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге каршындагы Иҗтимагый совет турындагы Нигезләмәне раслау хакында" карарына үзгәрешләр кертү турында»

2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә иҗтимагый контроль нигезләре турында»гы Федераль законның 13 статьясындагы 4 елеше нигезендә, Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2014 елның 16 декабрендәге 38-228 номерлы «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы" муниципаль берәмлеге каршындагы Иҗтимагый совет турындагы Нигезләмәне раслау хакында» карарына түбәндәге үзгәреш кертергә:

- № 1 кушымтаның 3.4 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге каршындагы Иҗтимагый совет составына Россия Федерациясе һәм Россия Федерациясе субъектларында дәүләт хезмәте вазыйфаларын башкаручы, Россия Федерациясе һәм Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче затлар һәм муниципаль хезмәт башкаручы һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затлар, шулай ук «Россия Федерациясенең Иҗтимагый палатасы турында» 2005 елның 4 апрелендәге 32-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы әгъзалары була алмый торган башка затлар керә алмый».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмати – телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru. бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм авыл җирлекләренең вәкиллекле органнары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә муниципаль районы
Башлыгы — В.М. Козлов